СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» март 2026 ел № 21

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советының 2024 елның 16 июлендәге 104 нче номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (29.11.2024 №116, 24.06.2025 №135 үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 567-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Балтач районы прокуратурасының 2026 елның 12 марттан 02-08-01-2026/Прдп97-26-209011 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында» 2024 елның 16 июлендә кабул ителгән 104 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турында Нигезләмәгә (29.11.2024 №116, 24.06.2025 №135 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) тикшереп торылучы зат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган критерийларга туры килми.»;

1.2. 3.5.6 пунктта «контроль (күзәтчелек) чаралары», сүзләрен «мәҗбүри профилактик визитлар,» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә тотылучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча»Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 № 248-

ФЗ Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.» ».

1.4. 3.5.1 пунктының «в » подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (әлеге Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә, федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә һәм муниципаль контроль төрләренә карата).»;

1.5. 3.5.1 пунктының 2 подпунктында «муниципаль контроль. Исемлек» сүзләрен «муниципаль контроль» яисә белешмәләре классификацияләнгән урнаштыру чаралары реестрына кертелгән контрольдә тотылучы затларга. Исемлек» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны интернетта - «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балтач муниципаль районының Келе Лызи авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы Л.М.Михайлова